Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

**2024 ел 02 апрелендәге** **№ 198**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Янгыннан саклау буенча социаль юнәлешле иҗтимагый берләшмәләргә һәм иректе янгын сүндерүчеләргә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2011 елның 24 октябрендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында иректе янгын күзәтчелеге турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 16 ноябрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Янгыннан саклау буенча социаль юнәлешле иҗтимагый берләшмәләргә һәм иректе янгын сүндерүчеләргә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2011 елның 24 октябрендәге 85 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 2 абзацында «хезмәткәрләрне һәм иректеләрне» сүзләрен «иректе янгын сүндерүчеләрне һәм янгыннан иректе саклау хезмәткәрләрен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык, ТКХ һәм төзелеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Советы рәисе Н.А.Вазыйхов